# Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге Советы

## КАРАР

**«16» март 2020 ел** **№157**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Шепкә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында» 2014 елның 13 нче февраль 124 номерлы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

"Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге Советы

**карар бирә:**

1. "Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында" 2014 елның 13нче февраль 124 номерлы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 16 статьяның 1 өлешендә:

1) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) коммерция яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу, түбәндәге очраклардан тыш:

а) сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппараты белән идарә итүдә, съездда (конференциядә) башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтенең гомуми җыелышында түләүсез нигездә катнашу;

б) коммерциячел булмаган оешма белән (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе

аппараты белән идарә итүдә, съездда (конференциядә) башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтенең гомуми җыелышында түләүсез нигездә катнашудан тыш) Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә яллаучы вәкиле рөхсәте белән түләүсез нигездә идарә итүдә катнашу;

в) Россия Федерациясе субъектының муниципаль берәмлекләре советында, башка муниципаль берәмлекләрнең берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә күрсәтү, яклау;

г) муниципаль берәмлекне гамәлгә куючы булып торучы идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючының вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яисә муниципаль милектәге акцияләр белән идарә итү тәртибен (устав капиталындагы өлешләр) билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә түләүсез нигездә тәкъдим итү;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;»;

2) түбәндәге эчтәлекле 3.1 пунктын өстәргә:

«3.1) эшмәкәрлек белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә;»;

1.2. 20 статьяның 3 өлешендә:

а) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) хезмәт кенәгәсен һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләрне (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66.1 статьясы), хезмәт килешүе беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;»;

б) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында, шул исәптән электрон документ рәвешендә теркәлүне раслый торган документ;»;

1.3. 29 статьяның 6 өлешендә «ә стаж озынлыгы һәм айлык түләүләр тиешле еллар эшләгән өчен пенсия күләмен кодекска ярашлы рәвештә билгеләгәндә муниципаль хезмәткәргә билгеләнгән шундый ук күрсәткечләрдә исәпкә алына» дигән сүзләрне «ә класс чины өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләр хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларын билгели торган норматив хокукый актында билгеләнгән күләмдә исәпкә алына.» дигән сүзләр белән алыштырырга;

1.4. 33 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Дисциплинар җәзаны куллану һәм алу тәртибе, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә.»;

1.5. 34 статьяның 9 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Әлеге нигезләмәнең 17, 19 һәм 33 статьяларында каралган җәза муниципаль хезмәткәр тарафыннан коррупциячел хокук бозу турында мәгълүмат кергән көннән алып алты айдан да соңга калмыйча, муниципаль

хезмәткәрнең вакытлыча эшкә сәләтсезлеге, чираттагы ялда булу вакытын санамыйча һәм коррупциячел хокук бозу көненнән өч елдан да соңга калмыйча кулланыла. Күрсәтелгән срокларга җинаять эшен әзерләү вакыты кертелми.”.

1.6. 42 статьяда:

1) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. 2020 елның 1 октябренә кадәр муниципаль хокукый актлар белән авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең (секретаренның) урынбасары вазыйфасын биләү өчен һөнәри белем дәрәҗәсенә карата квалификация таләпләре (урта һөнәри белем һәм муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажы) - кимендә ике ел яисә кимендә өч ел булуны күздә тота ала. 2020 елның 1 октябреннән соң кодексның 8 статьясы 3 өлеше 1 пунктында каралган күрсәтелгән вазыйфаны биләү өчен квалификация таләпләре 2020 елның 1 октябренә кадәр вазыйфага билгеләнгән һәм әлеге өлеш нигезендә кабул ителгән муниципаль хокукый актларда каралган тиешле квалификация таләпләренә карата кулланылмый.»;

2) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. 2022 елның 1 гыйнварына кадәр муниципаль хокукый актларда муниципаль хезмәт вазыйфаларының өлкән һәм (яисә) кече төркемнәре вазыйфаларын биләү өчен һөнәри белем дәрәҗәсенә карата квалификация таләпләре «Татарстан Республикасында тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары турында» 2015 елның 25 апрелендәге 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә муниципаль хезмәтнең тиешле вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычлары җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә катнашуга керә дип билгеләнгән очракта (урта гомуми белем булган очракта) күрсәтелми дип каралырга мөмкин.».

2. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Шепкә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында» 2016 елның 13 августындагы 37 номерлы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге Советының 2019 елның 18 сентябрендәге 142 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында, торак пункт территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Карар үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Совет рәисе урынбасары** **М.Г.Низамиева**